ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 10 от « 30 » январь 2020 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районының Мамадыш
шәһәренең Көнбатыш микрорайонында
линияле объект территориясен планлаштыру
һәм ызанлау проектын әзерләү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Көнбатыш микрорайоны чикләрендә урнашкан Гремячка, Е.Андронова, ген. Д. Карбышев,, В. Тимофеев, Н. Афанасьев, Салтыков-Щедрин, Ю.Курягин, Космановтлар, Яз (Весенняя), Бодай (Пшеничная), Москвин урамнарына газүткәргеч үткәрү линияле объектны ызанлау һәм планлаштыру» проектын әзерләү эшләрен башларга.

2. Әлеге карарны районның «Нократ» («Вятка») газетасында, интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарыга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Дөлмиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гарипов